Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ

№ 23 (36)

12 сентябрь 2012 ел



www.kpfu.ru

чыгарылышның тулы мультимедиа-version

UNIVERSMOTRI.RU

## Хөрмәтле беренче курс студентлары!

Сезне ихлас күңелдән олы максатыгызга ирешүегез – Казан университетына укырга керүегез белән тәбрик итәм.

Мөгаен, бу көннәрдә сездән дә бәхетлерәк, сездән дә күбрәк дулкынланган һәм дә илһамланган кешеләр юктыр. Без, укытучыларыгыз һәм остазларыгыз, сезнең бу шатлыкны һәм дулкынлануны уртаклашабыз. Университетыбызга яңа буын килгәненә сөенәбез, шул ук вакытта сезгә илебез өчен кирәкле, лаеклы белгечләр булырга ярдәм итә, актив гражданлык позицияләрен тәрбияли алырбызмы, дип тә борчылабыз. Әлбәттә, без моны бергәләп булдырырбыз.

Сез быел 208 яшен тутырган, Россиядә иң борынгы уку йортларының берсе булган университетның бусагасыннан атлап кердегез. Ике гасырдан артык тарихлы уку йорты 110 лап кешене дипломлы белгеч итте, аларның күбесе төрле эшчәнлек өлкәсендә зур үрләр яулап торалар. Федераль уку йорты дәрәҗәсен алгач, университет студентларны заманча белем бирү мөмкинлеге белән беррәттән реаль икътисад, IT-тармак, банк эшчәнлеге, идарә итү өлкәсендә өстәмә күнекмәләр һәм белемнәр белән дә тәэмин итә.

Бүгенге көндә университетның белем бирү структуралары реаль икътисад секторлары һәм халыкара фәнни белем бирү үзәкләре белән тыгыз бәйләнештә тора, ягъни уртак кафедралар, лабораторияләр эшләп килә, житештерү үзәкләре ачыла. Моннан тыш кече инновацион оешмалар да үз эшчәнлеген актив рәвештә алып баралар. КФУның фәнни белем бирү потенциалы турында безнең даими күрсәткечләр дә сөйли. Милек комплексыбызның гомуми мәйданы 776 мең кв. метрны тәшкил итә, 400 га якын җирдә 644 объект урнашкан (элек объектлар саны 312 иде). Студентлар саны 50 меңгә якынлашып бара, өч меңнән артык фәнни педагогик белгеч хезмәт куя. Шуны да әйтергә кирәк: аларның өчтән беренең күбесе 35 яшьтән дә өлкән түгел. Яңа фәнни белем бирү структурасы оештырылды (18 институт һәм өч факультет), алты лаборатория корпусы яңартылды һәм хезмәт күрсәтү өчен әзерләнде: бу 100дән артык яңа, шул исәптән, эксклюзив җиһазлар белән тәэмин ителгән лабораторияләр дигән сүз. Яңа икътисад өчен аеруча әһәмиятле саналган «инженер эше» буенча да уңышларбыз бар. Университетның инновацион инфраструктурасының үсешендә дә катнаша алырлык инженерларны әзерләүгә дә зур игътибар бирелә.



Быелгы беренче курс студентларына тагын бер яхшы яңалыгым бар. Түләүле бүлеккә кергән студентларга һәм магистрларга стипендия түләнәчәк. Приказ буенча, БДИда югары баллар җыеп, табигый-гамәли юнәлештә укырга теләүчеләргә (математика, механика, математик модельләү, физика, радиофизика, техник физика, химия), әмма түләүсез бүлеккә үтә алмаучыларга уку елының беренче семестрында ай саен түләнә торган стипендияләр билгеләнәчәк. Шартлары мондый: 1-5 балл җитмәгән очракта – тулы академик стипендия күләмендә, балл 5тән алып 10 га кадәр тулмаган очракта академик стипендиянең яртысы түләнәчәк. Билгеләнгән стипендияләр беренче имтихан сессиясен «әйбәт» һәм «бик яхшы» билгеләренә тәмамлаган очракта икенче семестрда да түләнергә мөмкин.


Сезнең өчен бик мөһим фикер җиткерәсем килә. Университетны тәмамлаганнан соң да сезгә даими рәвештә укырга, белем тупларга туры киләчәк, чөнки фән һәм мәгълүмат якынча һәр өч ел саен яңарып тора. Ул гына да түгел, хәзерге заман икътисады берничә мәртәбә һөнәрне, эш урынын алмаштыру тенденциясен тудырды. Уку йортын тәмамлаганнарның үз белгечлекләре буенча эшләмәве инде гадәти күренешкә әйләнеп бара. Шулай булгач, сез үзгәреп тора торган һәм конкурентлы икътисад шартларына җайлашырга, һәр эштә дә уңышка омтылырга һәм куйган максатларыгызга ирешә белергә тиеш. Университетыбызның физика факультетын тәмамлаган студентларның шәһәр мэрлары яисә зур компанияләрдә җитәкче булуларын, юридик факультетта укыган кайбер студентларыбызның Россиядә һәм җөмһүриятебездә министр дәрәҗәсенә үсеп җитүләрен мисал итеп китерергә була.

Әлбәттә, студент тормышы гел уку белән фәннән генә тормый. Ул шулай ук студентлар үзидарәсендә, кызыклы мәдәни вакыйгаларда, махсус яшьләр өчен уздырылган конкурс бәйрәмнәрдә катнашу да. Универсиада 2013 елда Казан шәһәрендә уздырылсын өчен, безнең студентлар күп көч түкте һәм шушы дөньякүләм спорт форумының әзерлегендә дә актив катнашалар. Сезгә Универсиададан калган мирасны үзләштерергә, аның спорт объектларын дөрес файдаланырга, волонтерлык хәрәкәтен дәвам итәргә һәм, гомумән, Казанны Россиянең башка шәһәрләре дә үрнәк алырлык актив, спорт сөючән, белемле, алдынгы карашлы яшьләр башкаласына әверелдерү өчен, үз өлешегезне кертергә туры киләчәк.

Университеттагы тормышыгызның беренче көннәреннән үк тәвәккәлләнеп эшкә керешсәгез иде, яшь дусларым! Куйган максатларыгызга омтылыгыз һәм сезнең барысы да килеп чыгачак. Мин, үз чиратымда, сезгә укуда, спортта, иҗатның төрле өлкәләрендә уңышлар һәм, иң мөһиме, тормышта лаеклы урын табуыгызны телим!

**Илшат ГАФУРОВ,**
**КФУ ректоры**


## Университет җитәкчелеге




Президент – **Сәлахов Мәкъзүм Хәлимуллович**
☎ 233-79-34,
✉ president@ksu.ru



Административ эшләр буенча проректор - аппарат җитәкчесе - **Хашов Андрей Николаевич**
☎ 292-73-26
✉ a-ha1964@mail.ru



Уку-укыту эшләре буенча проректор - **Минзарипов Рияз Гатауллович**
☎ 292-73-26
✉ a-ha1964@mail.ru




Фәнни эшчәнлек буенча проректор - **Нургалиев Данис Карлович**
✉ danis.nourgaliev@ksu.ru




Икътисади һәм стратегик үсеш буенча проректор - **Сафиуллин Марат Рәшитович**
☎ 292-78-57, 233-72-77
✉ lgudyaev@kpfu.ru




Финанс эшләре буенча проректор - **Муллакаева Рәйсә Рифовна**
☎ 233-70-71
✉ raisa.mullakaeva@ksu.ru




Хуҗалык эшләре буенча проректор – **Сафиуллин Ленар Солтангалиевич**
☎ 233-74-06
✉ lenar.safiullin@ksu.ru



Социаль һәм тәрбия эшчәнлеге буенча проректор – **Межведилов Ариф Магидинович**
☎ 231-54-29,
✉ amezhved@mail.ru



Инновацион эшчәнлек буенча проректор - **Кашапов Наил Фаикович**
☎ 233-79-06
✉ kashnail@gmail.com



Тышкы элемтәләр буенча проректор – **Латыйпов Линар Наильевич**
☎ 233-74-47
✉ linar.latypov@ksu.ru

## Казан федераль университеты ул:

- 21 институт һәм факультет.
- 3 югары мәктәп.
- 3 кадрларны яңадан әзерләү һәм белемнәрен арттыру үзәге.
- Якынча 50000 студент, шуларның 8000 КФУга быел кабул ителде.
- Якын һәм ерак көнчыгыштан 1000 студент, шуларның 400 артыгы быелдан КФУда белем ала башлады.
- 7600 артык хезмәткәр.
- 3000 артык укытучы.
- 52000 кв. м. мәйдан алып торучы укыту-лаборатория үзәкләре.
- 13 спорткорылмасы, шуларның иң олылары: «Мәскәү», «Бустан», «Уникс».
- 4 шәһәр читендә урнашкан лагерь.
- Җәмәгать туклану һәм сату комбинаты.

## КФУ үсешенең өстенлекле юнәлешләре:

- Нефть эшкәртү һәм нефть химиясе
- Яңа җиһазлар һәм нанотехнологияләр
- Мәгълүмати-коммуникацион технологияләр һәм инфраструктура
- Биологик һәм медицина технологияләр







Сәхнәдә - «Мизгел» театры

# Биредә ШӘХЕСләр тәрбияләнә

Татар халкы борынгыдан ук мәдәнияткә, телгә, сәнгатькә гашыйк милләт булган. Бүген дә горур итеп, ныклы адымнар белән алга атлый. Үткән белән бүгенгене тоташтыру, милләтебезнең бөтен хәзинәсен саклап, киләчәккә тапшыру өчен яшь буын җаваплы.

Университетыбызның татар филологиясе бүлеге башкаларыннан миллилеге, тыйнаклыгы белән аерылып тора. Телебезнең бөтен байлыгын өйрәнеп бетү өчен 5 ел вакыт кына да җитми. Студентларны күпкырлы шәхес итеп тәрбияләүгә, укытучылар бөтен көчләрен куя. Алар сезгә төпле белем һәм ныклы тәрбия бирүдән тыш, якын кешеләрегезгә, киңәшчеләрегезгә әвереләләр.

Һәр курс саен уздырыла торган **«Фольклор»**, **«Диалектология»**, **«Музей»** практикалары алган белемнәрегезне ныгыту, туган ягыбыз үзенчәлекләрен өйрәнү, анализлау өчен ярдәм итәр. 4 курста педагогик практика узганнан соң, сайлаган һөнәрегезнең ни дәрәҗәдә җаваплы һәм кызыклы икәнен тагын да ныграк аңларсыз.

Студент тормышы гел уку, зачет-имтиханнарга гына кайтып калса, бер дә күңелле булмас иде. Үзләрен иҗат, җыр-бию, спорт өлкәсендә сынап карарга теләгән студентлар өчен факультетыбызда барлык мөмкинлекләр дә тудырылган. **«Илһам»**, **«Әллүки»** әдәби-иҗат берләшмәсе әгъзалары үзләренең иҗади осталыкларын тагын да камилләштерә алыр. **«Киномания»**, **«Милли хәзинә»**, **«Ягымлы яз»** фестивальләрендә дә бүлек студентлары сынатмый. Волейбол, баскетбол, кул көрәше, җиңел атлектика буенча да уңышлар мактанырлык.



Татар филологиясе бүлеге мөдире
**Сәйфулина Флера Сәгыйть кызы**
Телефон: (843) 292-58-11, 221-33-38.
Адрес: Казан шәһәре, Татарстан ур., 2 (№33 уку бинасы)




«Милли хәзинә» фестивалендә катнашучылар Шигырь бәйрәмендә



«Илһамлы каләм» конкурсыннан



Бию ансамбле




Киномания фестивале



Татар филологиясе хоры

# Адашмас өчен

**Шартлы билгеләр**

- Уку корпусы
- Филиал
- Спорт корылмалары
- Тулай торак
- Китапханә уку зал
- Актлар залы
- Ашханә, буфет
- Wi-Fi зонасы
- Банкомат
- Канцтоварлар
- Велосипед стоянкасы
- Почта

## Геология һәм кара алтын-газ технологияләре институты

*Кремль ур., 4/5*



## Идарә иту һәм территориаль үсеш институты
## Өзлексез белем бирү институты

*Кремль ур., 6/20*



## КФУның та…

(К…

Фундаменталь медицина һәм биология институты
Юридик факультет
КФУ администрациясе
Матбугат үзәге

*КФУның төп бинасы, Кремль ур., 18*



## Физика институты

*Кремль ур., 16 а*



Экол…


исем… һәм …
Хиса…

техн…

## Филология һәм сәнгать институты:

Тәрҗемә һәм мәдәниятара бәйләнешләр бүлеге
Роман-герман филологиясе бүлеге
Татар филологиясе бүлеге
Директорат

*Татарстан ур., 2*



## Филология һәм сәнгать институты:

Рус филологиясе бүлеге
Сәнгать бүлеге


*Межлаук ур., 3/45*



## Мәгълумати системалар һәм технологияләр югары мәктәбе
## КФУның «Univer» Медиа-Үзәге

Газета редакцияләре:
«Казанский университет», «Darelfөnүn», Univer-TV







1. Төп бина.
2. Ректор бинасы, элек Н.И. Лобачевский яшәгән йорт (хәзер «механичка»).
3. Геометрик корпус.
4. Криоген корпус.
5. Астрономия кафедрасы.
6. Н.И.Лобачевский исемендәге фәнни китапханә (иске бинасы).
7. Сирәк китаплар һәм кульязмалар бүлеге.
8. Анатомик театр.
9. А.М.Бутлеров исемендәге НИХИ.
10. Казан Император университетының медицина факультеты лабораторияләренең элекке бинасы, хәзер КДМУның 3 уку корпусы.
11. Көнбатыш ярымциркуль.
12. Атом-төш физикасы лабораториясе.

## Көнчыгышны өйрәнү һәм халыкара бәгланышлар институты
## Фәлсәфә факультеты

*Пушкин ур., 1/55*



## Педагогика һәм психология институты

*Межлаук ур., 1*



## Журналистика һәм социология факультеты

*Товарищеская ур., 5*



## Физик тәрбия һәм тернәкләндеру медицинасы институты

*Сул Болак ур., 44*



## Экология һәм география институты

*Сул Болак ур., 34*




## «Мәскәү» спорткомплексы

*Мәскәү ур., 49*



## арихи үзәге
ГУ)



А.М.Бутлеров исемендәге Химия институты

*Лобачевский ур., 1/29*

огия һәм география институты

Н.И.Лобачевский ендәге Математика механика институты,

плау математикасы һәм мәгълүмати ологияләр институты,

Тел институты

***II корпус Кремль ур., 35***






13. Көнчыгыш ярымциркуль.
14а. УНИКС, мәдәни комплексы.
14б. УНИКС, спорт комплексы.
15. Мәгълүмати технологияләр үзәге бинасы.
16. ТР Милли китапханәсе.
17. Икенче уку корпусы.
18. Н.И.Лобачевский исемендәге фәнни китапханә.
19. А.М. Бутлеров исемендәге Химия институты.
20. Физика институты.
21. Сковородка.

UNIVERSMOTRI.RU

Университет буенча 3D сәяхәтне kpfu.ru/univer_tv/video/video3.phtml?uniq=204 сылтамасы буенча карый аласың.

### Тарих институты

*К.Маркс ур., 74*



### Икътисад һәм финанс институты

*Бутлеров ур., 4*



### «Бустан» спорткомплексы,

*Кулагин ур., 8а*




«Бустан» бассейны



### Универсиада авылы



Универсиада авылы



Теннис академиясе



«Буревестник» бассейны

## Алабуга институты

***Алабуга ш., Казан ур., 89***

**Факультетлар:**
Биология
Технология-инженерия
Чит телләр
Тарих һәм юриспруденция
Психология һәм педагогика
Рус филологиясе һәм журналистика
Татар һәм чагыштырма филология
Физик культура
Икътисад һәм идарә
Физик-математик



## Яр Чаллы филиалы

***Яр Чаллы ш., Сөембикә пр., 10а***



**Факультетлар:**
Юридик
Икътисад
Гамәли математика һәм мәгълүмати технологияләр
Чит телләр
Филология һәм журналистика

## КФУның структур бүлекчәсе (элекке ИНЕКА)

***Яр Чаллы шәһәре, Тынычлык проспекты, 68/19***

Автоматизация һәм прогрессив технологияләр факультеты
Автомеханика факультеты
Архитектура, төзелеш һәм дизайн институты
Читтән торып уку факультеты
Икътисад факультеты
Укытучыларның һәм белгечләрнең квалификациясен арттыру факультеты
Дистанцион укыту һәм халыкара программалар институты
Чистай филиалы




## Яшел Үзән филиалы

***Яшел Үзән ш., С.Сәйдәшев ур., 4***



**Факультетлар:**
Физик-математик
Гуманитар

# Тәрҗемә серләре



Тәрҗемә һәм мәдәниятара бәйләнешләр бүлеге мөдире **Юсупова Әлфия Шәфкать кызы**
Телефон: (843) 291-33-99
Адрес: Казан шәһәре, Татарстан ур., 2 (№33 уку бинасы)

КФУның Филология һәм сәнгать институтының тәрҗемә һәм мәдәниятара бәйләнешләр бүлеге 2011-2012 уку елында гына татар филологиясе факультетыннан аерылып чыгып, үзенең беренче адымнарын ясады. Алга таба аның үсешкә ирешүенә нәкъ менә син дә йогынты ясый аласың.

Бүлекнең төп максаты – тәрҗемәчеләр әзерләү. Ул, тәрҗемә теориясенә һәм практикага бәйле, ике юнәлештә тормышка ашырыла: чит телләр – инглиз һәм европа телләре, рус теленнән – татар теленә, татар теленнән рус теленә тәрҗемә итү.

Бүлектә эшләп килә торган «Тәрҗемә һәм сөйләм культурасы» фәнни түгәрәгенә йөреп, тәрҗемә нигезләре белән танышырга, сөйләм культурасын үстерергә мөмкин. «Студентлар тәрҗемәнең төп юнәлешләре, төрле классификацияләр, тәрҗемә тарихы белән таныша. Рус теленнән татар теленә тәрҗемә итүнең теоретик һәм гамәли нигезләрен өйрәнә. Алман, инглиз телләреннән татар теленә тәрҗемә иткән эшләр дә бар», – ди фәнни җитәкчеләре филология фәннәре кандидаты, доцент Зоя Кириллова.




# «Аңны тәртипкә китерик»



Математика фәне барлык фәнни дисциплиналарның нигезе булып тора. Аның әһәмиятенең ни дәрәҗәдә мөһим икәнен XVIII гасырда ук бөек галим Михайло Ломоносов әйтеп калдырган: «Математиканы аңны тәртипкә китергәне өчен генә булса да яхшылап өйрәнергә кирәк», – дигән. Дөрестән дә, берничә өлкәдә яхшы белгеч булырга теләсәң, математик белем ныклы булырга тиеш.

Казан федераль университетының Н.И.Лобачевский ис. математика һәм механика институтына укырга кергән студентлар мондый сайлау ясауларының ни дәрәҗәдә уңышлы икәнен укый башлагач тагын да ныграк аңлар. Бай тәҗрибәле укытучылар ярдәмендә кызыклы һәм мавыктыргыч студент тормышының ничек тиз узганын сизми дә калырсыз!

Институтның тагын бер зур әһәмиятле ягы бар: педагогик белем бирү бүлеге ТДГПУның бай тарихлы физика-математика факультеты базасында барлыкка килде. Әлеге бүлектә мәгариф өлкәсе өчен математика һәм информатика юнәлешендә югары квалификацияле белгечләр әзерләнә. Педагогик кадрлар әзерләү бик тыгыз рәвештә фәнни-тикшерену эше белән берлектә башкарыла. Бүлекнең тагын бер әһәмияте: биредә туган телебездә белем ала торган төркемнәр бар.



Н.И.Лобачевский ис. математика һәм механика институтының педагогик белем бирү бүлеге мөдире **Зарипов Фәрхәт Шәүкәт улы**
Телефон: 233-73-43
Адрес: Казан шәһәре, Кремль ур., 35

# Беренче курслар өчен календарь!





**Сентябрь**
- Беренче курс студентларының университет җитәкчелеге белән очрашуы
- Студентлар тормышы буйлап экскурсия (концерт программасы)



**Октябрь**
- Беренче курслар бәйрәме
- Беренче курслар спартакиадасы
- «Сәлам, талантлар» һәм «Бер адым алга» актив мәктәбе



**Ноябрь**
- Университетның туган көне
- КФУның КВН Лигасы махсус проекты



**Декабрь**
- Ел дәвамында уздырыла торган «КФУның Ел студенты» конкурсына йомгак ясау



**Гыйнвар**
- Студентлар бәйрәме, ягъни «Татьянин день»



**Февраль**
- Сәламәтлек поезды
- Иҗат яшьләренең «Байтик» слеты
- КФУның КВН Лигасы фестивале



**Март**
- Студентлар язы
- «Точка зрения» халыкара фәнни-гамәли конференциясе



**Апрель**
- «Сәламәт тәндә - сәламәт акыл» девизы астында уздырыла торган сәламәтлек көне



**Май**
- Җиңү бәйрәме. Уку йортыбыз ветераннарын хөрмәтләү тантанасы



**Июнь**
- Яхшы билгеләргә тәмамлаган чыгарылыш курс студентларына кызыл диплом тапшыру тантанасы



**Июль**
- Иҗат яшьләренең «Креативный бум» слеты

# «Журналистикада тау артында калып булмый»

Алинә САДЫЙКОВА

ЖУРНАЛИСТИКА ФАКУЛЬТЕТЫ ИНДЕ НИЧӘ ЕЛЛАР ДӘВАМЫНДА ИЛЕБЕЗГӘ ЛАЕКЛЫ, ЮГАРЫ БЕЛЕМЛЕ ЖУРНАЛИСТЛАР ӘЗЕРЛИ. ӘЙТЕРГӘ КИРӘК, АЛАРНЫҢ КҮБЕСЕ САЙЛАГАН ҺӨНӘРЛӘРЕНӘ ТУГРЫ КАЛАЛАР. ШУЛАЙ ДА ХЕЗМӘТЕН ЧЫН МӘГЪНӘСЕНДӘ ЯРАТЫП, БАШКАЛАРГА ҮРНӘК БУЛЫРДАЙ ПРОФЕССИОНАЛЛАР БАРМАК БЕЛӘН САНАРЛЫК. ЖУРНАЛИСТИКА ФАКУЛЬТЕТЫНДА БЕЛЕМ АЛГАН, ХӘЗЕРГЕ КӨНДӘ АНДА ҮЗЕ БЕЛЕМ БИРҮЧЕ, «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» ГАЗЕТАСЫНЫҢ БАШ МӨХӘРРИРЕ МИНҢАЗЫЙМ МӘҮЛЕТ УЛЫ СӘФӘРОВ ШУНДЫЙ БЕЛГЕЧЛӘР РӘТЕНЕҢ БЕРЕНЧЕ САФЛАРЫНДА ТОРА.





Журналистика һәм социология факультеты деканы
**Гарифуллин Васил Заһит улы**
Телефон: (843) 200-09-11
Адрес: Казан шәһәре, Товарищеская ур., 5.

**– Миңназыйм Мәүлетович, Сезнең журналист сәләте кайчан ачылды?**

– Теләсә-нинди кеше дә «журналист буласым килә», – дип кенә бу һөнәр иясе булып китә алмый. Кешедә ниндидер бөре, язуга хирыслык булырга тиеш. Мин инде 7-8 сыйныфларда укыганда ук, журналист буласымны белә идем. 4 класста укыганда, беренче шигырьләремне иҗат иттем. Соңрак район, шул ук вакытта «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») газеталарында басыла башладым. Беренче интервью алганымны бүгенгедәй хәтерлим әле: 8 сыйныфта вакытта үзебезнең авыл басуына чыгып, бер комбайнчыны туктатып, аннан сорашып, сөйләшеп торган идем. Таныш абый булса да, оялдым, уңайсызландым. Инде югары сыйныфларда журналистика факультетына керәм, дип махсус әзерләндем. Кая барасымны, үземә ни кирәген төгәл аңладым.

**– Студент елларыгыз нәрсәсе белән истә калды?**

– Миңа, авылдан килгән балага, университет бик күпне бирде. Бу елларны мин «өйрәнчек еллар» – язарга өйрәнү еллары диеп атар идем. Мәктәптә язу ул бер хәл, ә тормышны танып белеп, ситуациягә үз мөнәсәбәтеңне белдереп язу – вакыт белән бирелә торган әйберләр. Белемне дә үзең теләсәң генә алып була. Ул тырышлык, омтылыш ярдәмендә алына торган байлык. Безне төркемебез белән район газеталарына практикага җибәрәләр иде. Үз теләгебез белән дә төрле радакцияләргә практикага йөри идек. «Каз канаты» бию ансамбленә йөрергә дә вакыт таба идем. Кыскасы, тулы студент тормышы белән яшәдем.

**– Шундый актив тормыш алып баргач, Сезгә эшчәнлегегезне башлап җибәрергә дә кыен булмагандыр?**

– Мин студентларыма гел: «Укыганда ук үзеңне күрсәтергә кирәк», – дип әйтәм. Максатчан эшләгән кешене һәрвакыт күрәләр һәм аңа аннары кулына диплом тотып эш эзләп йөрергә туры килми. Безнең очракта студентларыбыз практикада сынала. Мине дә «Татарстан яшьләре»ндә практика үткәндә күреп калганнар һәм вакытлыча декретка киткән хатын урынына эшкә чакырдылар. Анда килгәч, кемнең кул астына эләгәсең бит әле. Әгәр остазың сиңа вакытында канатлар куя алса, беренче адымнарыңны ясаганда дөрес юл күрсәтүче булса, эшләп китәргә бик җайлы була. «Татарстан яшьләре» редакциясе хезмәткәрләре – чын мәгънәсендә юл күрсәтүчеләрем, укытучыларым булды. Менә шулай, вакытлыча диеп килгән эшемдә 30 ел эшләдем. Быел инде «Ватаным Татарстан»га килгәнемә дә 9 ел була. Шулай итеп, үз гомеремдә ике эш алыштырдым мин. Журналистикада тау артында калып булмый: фамилияңне язасың да, үз өстеңә җаваплылык аласың, монда бөтен әйбер дә күз алдында. Тагы шунысы да бар: журналистикада җитәкче булмый, ул – бик шартлы төшенчә. Безнең очракта ул идарә итү, кемнедер әрләү түгел, ә иҗадилык, кеше язганны аңлый, хаталарын төзәтә белү, дигән мәгънә ала.

**– Сез бүгенге көндә үзегез дә журналистика факультетында укытасыз. Сез укырга кергән һәм хәзерге факультет арасында аерма бармы?**

– Аерма, һичшиксез, бар. Безне Совет системасы вакытында укыганда: «Күтәрелеп чыкма», «әйткәнне тыңла», «кеше белән тигез бул», «артыгын сөйләшмә, артыгын күрмә», – дигән кагыйдәләрдән чыкмаска өйрәттеләр. Ә бүгенге студент курыкмыйча ни уйлаганын әйтә, бәхәсләшә ала. Мин моны нормаль күренеш дип саныйм. Шуңа күрә мин дә күп укыйм, яшьләр белән аралашырга яратам, кайбер сыйфатларын үзләштерергә тырышам. Аңа гына да түгел, студентлар миңа тонусны тотар өчен кирәк. Мин аларга коллегаларыма шикелле карыйм. Үземнең хаталарны сөйлим, тәҗрибәм белән уртаклашам. Без ясаган ялгышларны яңа буынга ясатасы килми. Шунысы да бар: әгәр кеше яшьләрнең хаталарын саный, аларны тәнкыйтьли икән – кеше картая, ә актив журналистика ул яшьләр өчен.

**– Әңгәмәбез ахырында беренче курс студентларына нинди теләк-киңәшләр әйтер идегез?**

– Журналист ул – кызыксыну, ситуацияне аңлау, кешегә якын килә, аны тыңлый белү, ягъни психолог булу, дигән сүз. Журналистика үзе мәгълүмат туплау, чагыштыру һәм нәтиҗә ясаудан җыела. Күп кеше мәгълүматны интернеттан ала, әмма ул гына җитми. Яхшыны начардан, акны карадан аеру өчен төпле белем кирәк, ә ул, үз чиратында, бик күп тырышлык таләп итә. Барысы да кешенең үз кулларында, үз теләгендә. Иң мөһиме, вакытында үзеңә ни кирәк икәнен аңларга һәм куйган максатыңа ирешү юлларын эзләргә кирәк.





**Алия Какорина, КФУның Матбугат үзәге фотохәбәрчесе:** «Кадерле беренче курс студентлары! Сезне Республикабызның иң абруйлы университетының студентлары булуыгыз белән тәбриклим. Мин үзем дә әлеге факультетны тәмамладым, шуңа да тулы ышаныч белән әйтә алам: журфак студентлары барлык вакыйгалар үзәгендә кайныйлар. Сез инде беренче курстан ук бу һөнәрнең нигезләренә төшенә башлаячаксыз. Студент еллары бик тиз узып китәр, менә хатирәләр гомер буе сакланачак»!

**Рөстәм Исхаков, «Татарстан» телерадиокомпаниясе журналисты:** «Яшь коллегаларым, беренче курстан ук яхшылап белем алыгыз, университет тормышында актив катнашыгыз, журналист буларак языгыз-сөйләгез, радио-ТВда чыгыш ясагыз. «Әй, вакыт бар әле, алда биш ел», — дип уйлый күрмәгез, чөнки нәкъ менә студент булганда, сез шәхес булып формалашасыз. Тик гади буласы килми, шуңа күрә университет биргән бар мөмкинлекне кулланып калырга тырышыгыз. Теләгем шул: журфак данын онытма, дан эшләүдән курыкма»!

**Наилә Бадыкшанова, КФУның Матбугат үзәге хезмәткәре:** «Сез зур конкурсларны үтеп, иң кызыклы факультетларның берсенә — журналистика һәм социология факультетына кердегез. Сезне алда мавыктыргыч паралар, танылган журналистлар белән очрашулар, күп ачышлар һәм кызыклы вакыйгалар көтә. Язган язмаларыгыз, әзерләгән тапшыруларыгыз һәрвакыт үзегезгә кызыклы булсын һәм һәр әйткән, һәр язган сүзегез өчен җаваплы булуыгызны онытмагыз. Хәерле сәгатьтә»!

## Схема 2. Казан шәһәрендә КФУ төп биналарының урнашу тәртибе

КФУ ның төп бинасы,
*Кремль ур., 18*
Фундаменталь медицина һәм биология институты,
Юридик факультет

А.М.Бутлеров исемендәге Химия институты,
*Лобачевский ур., 1/29*

II корпус
*Кремль ур., 35*
Экология һәм география институты,
Н.И.Лобачевский исемендәге Математика һәм механика институты,
Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институты,

Мәгълүмати системалар һәм технологияләр югары мәктәбе,
КФУның «Univer» Медиа-Үзәге
Газета редакцияләре: «Казанский университет», «Darelfønyn», Univer-TV
*Проф.Нужин ур., 1/37*

УНИКС мәдәни-спорт комплексы
*Проф.Нужин ур., 2*

Тарих институты
*К.Маркс ур., 74*

Журналистика һәм социология факультеты
*Товарищеская ур., 5*

Геология һәм кара алтын-газ технологияләре институты,
*Кремль ур., 4/5*

Идарә итү һәм территориаль үсеш институты,
*Кремль ур., 6/20*

Физика институты
*Кремль ур., 16 а*

Физик тәрбия һәм тернәкләндерү медицинасы институты,
*Сул Болак ур., 44*

Педагогика һәм психология институты,
*Межлаук ур., 1*

Филология һәм сәнгать институты,
*Межлаук ур., 3/45*

«Мәскәү» спорткомплексы,
*Мәскәү ур., 49*

Көнчыгышны өйрәнү һәм халыкара багланышлар институты, *Пушкин ур., 1/55*

Фәлсәфә факультеты,
*Пушкин ур., 1/55*

Филология һәм сәнгать институты,
*Татарстан ур., 2*

Икътисад һәм финанс институты,
*Бутлеров ур., 4*

«Бустан» спорткомплексы,
«Бустан» бассейны,
*Кулагин ур., 8а*

Универсиада авылы,
«Буревестник» бассейны,
Теннис академиясе




Универсиада авылына бару схемасы (47 нче номерлы маршрут)

# Студент сүзлеге

◆ **УНИВЕРСИТЕТ** төшенчәсе безгә алман телендәге «Universitet» сүзеннән килеп кергән, ә алманлылар аны, үз чиратында, латиннардан («universitas» – җыелма, уртаклык) үзләштергәннәр. Сүз унаеннан, дөньяда иң беренче Университет б.э.к. 700 елда Һиндстанның Таксила шәһәрендә (хәзерге Пакистан территориясе) оешкан. Анда 10500дән артык студент 60ка якын фән нигезләре белән танышкан.

◆ Беркемгә дә сер түгел, **СТУДЕНТ** – бөтен көчен түгеп, бар күңелен биреп, җиңен сызганып белем алырга омтылып яшәүче кеше. Бу атаманың латин телендәге «studio» (тырышып эшләүче) сүзеннән килеп чыгуы да гаҗәп түгел. Аны беренче булып Афинага яңа белем тупларга килгән Овидий үзенә карата кулланган.

◆ **СТИПЕНДИЯ** сүзен шулай ук латин теленнән «алып» торганнар. Алуын алганнар да кире бирергә онытканнар. Шуңа күрә бүгенге көндә дә без бу атаманы кулланабыз. Тамыры «пендо» – «үлчим» дигән сүздән алынган. Борынгы Римда хезмәт хакын, гадәттә, граммлап үлчәп биргәннәр. Студентлар өчен айлык пособие атамасы тарихы да шул күренешкә барып тоташа.

2012/13 уку елының 1 семестрына

**Дәресләр тәртибе**

8.30 - 9.50
10.00 - 11.20
11.30 - 12.50
13.05 - 14.25
14.40 - 16.00
16.10 - 17.30
17.40 - 19.00
19.10 - 20.30
20.40 - 22.00

DARELFØNYN
УНИВЕРСИТЕТ
Махсус чыгарылыш

Тираж 1000

Баш мөхәррир – Илдар Азат улы Кәримов
Иҗат коллективы: Д.Р.Әхмәтова, А.Ю.Садыйкова, Р.Г.Ханнанов
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч – Г.З.Камалиева
Фотохәбәрчеләр: А.Галимуллина, Ә.Фазлыйәхмәтов, Р.Газизов
Номерны әзерләгәндә Д.Р.Әхмәтова, А.Ю.Садыйкова, Г.З.Камалиева идеяләре файдаланылды

Газета бушлай таратыла

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 10.00. «Карти» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Восстание ур., 60 й.